# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 18.11.2021

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә" 2021 нче елның 18 нче ноябрендә " 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300,00(өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмәсе төзелде, моннан тыш, I төркем инвалидларыннан, хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга Сез ризамы:
- Дружба авылы зират территориясе янындагы күперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Дружба авылы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу

-Ләке авыл җирлегендә "Питрау" бәйрәме уздыру өчен призлар, бүләкләр алу "ӘЙЕ", "ЮК".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 36 катнашучы кертелгән, җыенында катнашучылар саны 20 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
"ӘЙЕ" позициясе өчен җыенда катнашкан 20 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан , хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге уку йортлары студентларыннан тыш 2022 елда үзара салым кертергә риза :

- Дружба авылы зират территориясе янындагы күперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Дружба авылы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу

-Ләке авыл җирлегендә “Питрау” бәйрәме уздыру өчен призлар, бүләкләр алу кабул ителде.

3. Әлеге караны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Ләке авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче ____________________ Шәрипова Л. И.